| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ШАРЛИАРЕМИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ № 4 КАРАР

8 ноябрь 2021 ел

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, 18.1 статьясы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Уставы нигезендә:

1.Сөлек авылы клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 18 ноябренә 13 сәгать 00 минутта билгеләргә.
2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I төркем инвалидларыннан тыш, 2022 елда 350 сум үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге уку йортлары студентларыннан һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:
- Сөлек авылында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
-МТЗ-320,4 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт өчен түләү);
- бәйрәмнәрне үткәрү өчен бүләкләр (Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, 9 Май);
- Сөлек авылында Бөек Ватан сугышы ветераннары йортына мемориаль такта сатып алу;
- Сөлек авылында зират территориясен эйләндеру очен материаллар сатып алу

«ӘЙЕ»ЮК".
3 Әлеге карарны 7 кон эчендэ «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) («Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында) (http://sarmanovo.tatarstan.ru Шэрлэрэмэ авыл жирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга..
4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы
Сарман муниципаль районы башлыгы Н.Н.Хуҗина